ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«30» ноября 2022 ел № 802

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы авыл җирлекләренең җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юллары, урам-юл челтәре исемлеген раслау турында» 08.02.2022 елның 28 номерлы Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының карарына үзгәрешләр кертү хакында (03.08.2022 елның 173 номерлы карар редакциясендә)

"Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" 2007 елның 08 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль законны һәм «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» 2009 елның 3 августындагы 43 – ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын, Әгерҗе муниципаль районы автомобиль юллары исемлеген актуальләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы авыл җирлекләренең җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юллары, урам-юл челтәре исемлеген раслау турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 08.02.2022 елның 28 номерлы карарына кертелә торган үзгәрешләрне расларга (03.08.2022 елның 173 номерлы карар редакциясендә).

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында урнаштырырга (https://agryz.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары вазыйфаларын башкаручы К. М. Сотовка йөкләргә.

**Җитәкчесе** **Р. Р. Шәрипов**

Татарстан Республикасы Әгерҗе
муниципаль районы башкарма
комитетының
30.11.2022 № 302
карары белән расланды

**«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы авыл җирлекләренең җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юллары, урам-юл челтәре исемлеген раслау турында» 08.02.2022 елның 28 номерлы Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының карарына үзгәрешләр кертү (03.08.2022 елның 173 номерлы карар редакциясендә)**

1. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы авыл җирлекләренең җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юллары, урам-юл челтәре исемлеген раслау турында» 08.02.2022 елның 28 номерлы Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 нче кушымтаның 218 нче пунктын (Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы авыл җирлекләренең һәм Әгерҗе шәһәренең урам-юл челтәре исемлеге) киләсе редакциядә бәян итәргә:

| Т/с | Автомобиль юлының атамасы | Юлның идентификация номеры | | Озынлыгы, км | | | | барлыгы | Мәйданы, кв.км | | | | Файдалануга тапшыру елы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | ц/б | а/б | Вак таш, гравий | грунт | | ц/б | а/б | Вак таш, гравий | грунт | |
| 218 | К.Маркс урамы | 92-201-872 ОП МП 92-000 | 1,622 | | | 1,622 | | 0,006488 | | | 0,006488 | | |